КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 июль г.Казань № 781

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең 6 нчы – 12 нче разрядлары буенча тариф ставкаларына арттыру коэффициентларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 21 ноябрь, 547 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләре өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең 6 нчы – 12 нче

разрядлары буенча тариф ставкаларына арттыру коэффициентларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 21 ноябрь, 547 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 декабрь, 643 нче; 2007 ел, 18 октябрь, 575 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарның кушымтасы исемендә «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин